СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ

ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №96 (7269) | 10 август, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91“ пресс-группасы хәбәр итә

Районда урып-җыю тәгәлләнү алдында тора. 9 нчы августка барлыгы 43712 гектарда бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар уңышы җыелды. Бу барлык мәйданның 82 проценты дигән сүз.

7367 гектар, ягъни 88 процент җирдән солы, ә 2945 гектардан арпа җыелган, ул барлык җирнең 84 процентын тәшкил итә. Сабан бодае районлагы җирләрнең яртысыннан җыелды.

Барлыгы 14601 гектарда туңга сөрү үткәрелде, планга карата 60 процент азык хәзерләнде.

Хуҗалыкларда уҗым культуралары чәчү 771 гектарда башкарылды.

# ИРТӘГӘ—ТӨЗҮЧЕЛӘР КӨНЕ



Рәсемдә: Т. Г. Ишкальдина кызлары.

(Район төзүчеләренең күркәм эшләре турында газетаның 2—3—4 битләреннән укыгыз).

## ДАН ФЛАГЫ КҮТӘРЕЛӘ

Соңгы өчкөнлек нәтиҗәләре буенча район үзәгендә Дан флагы «40 лет Победы» колхозы комбайнчысы Хәмит Кашапович КЫЯМОВ хөрмәтенә күтәрелде. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында 9 мең центнерга якын ашлык суктырып, район комбайнчылары арасында әйдәп бара.

## Кыр батырларына тигезләнегез!

## Районның ашлык суктыруда иң әйбәт күрсәткечләргә ирешкән алдынгы комбайнчылары

Беренче багана—токтан урыны, икенче—исем—фамилиясе, өченче — хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан суктырылган бөртек (центнерларда). (Мәгълүматлар 1991 елның 9 августына).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 8808 |
| 2. | Абрамов В. Д. | «Восход» | ДОН-1500 | 8358 |
| 3. | Донсков А. Е. | «Большевик» | ДОН-1500 | 8037 |
| 4. | Сафин Ә. Ә. | Ульянов исем. | ДОН-1500 | 6550 |
| 5. | Нилов Н. В. | Синдряков исем. | ДОН-1500 | 6100 |
| 6. | Хәсәнҗанов Н. Г. | «Чишмә» | ДОН-1500 | 5815 |
| 7. | Бикиев С. З. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 5500 |
| 8. | Абдрахманов Р. А. | «Игенче» | ДОН-1500 | 5420 |
| 9. | Сөнгатуллин В. В. | «Таң» | СК-5 | 5400 |
| 10. | Ситдыйков С. Ш. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 5130 |
| 11. | Абдуллин И. Ә. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 5100 |
| 12. | Хәлимов М. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 4927 |
| 13. | Ибраһимов Ә. И. | «Игенче» | ДОН-1500 | 4910 |
| 14. | Закиров И. Г. | «Таң» | СК-5 | 4900 |
| 15. | Казаков Ю. А. | «Заря» | ДОН-1500 | 4893 |
| 16. | Матвеев В. А. | «Алга» | СК-5 | 4705 |
| 17. | Вафин Р. Р. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 4603 |
| 18. | Нуруллин Р. Ә. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 4420 |
| 19. | Шәрәков Ф. Г. | «Алга» | СК-5 | 4380 |
| 20. | Фәттахов Ф. Ф. | «Алга» | СК-5 | 4298 |

## 1991 нче ел уңышын уру алдынгылары

Беренче багана—токтан урыны, икенче—исем—фамилиясе, өченче—хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан күпме урдырылган (гектарларда). (Мәгълүматлар 9 августка).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәфигуллин Р. З. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 813 |
| 2. | Алиев С. Х. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 654 |
| 3. | Хәлиуллин В. Х. | «Таң» | СК-5 | 580 |
| 4. | Әхсәнов С. З. | «Игенче» | СК-5 | 565 |
| 5. | Демьянов Е. М. | «Восход» | СК-5 | 516 |
| 6. | Шәйдуллин И. Б. | «Комбайн» | СК-5 | 480 |
| 7. | Захаров Л. С. | «Мамык» совхозы | СК-5 | 470 |
| 8. | Зиннуров Ш. Р. | «Игенче» | СК-5 | 465 |
| 9. | Бильданов Н. М. | «Чишмә» | СК-5 | 460 |
| 10. | Алексеев А. В. | «Сөлчә» совхозы | СК-5 | 457 |
| 11. | Хәсәнов М. Р. | «Таң» | СК-5 | 450 |
| 12. | Родионов А. В. | Синдряков исем. | СК-5 | 430 |
| 13. | Миннеголов С. Х. | Муса Җәлил исем. | СК-5 | 420 |
| 14. | Захаров В. А. | Синдряков исем. | СК-5 | 405 |
| 15. | Волков В. Я. | «Заря» | СК-5 | 393 |

## *Газетага язылу дәвам итә*

Илдәге киеренке хәл, базар мөнәсәбәтләренә күчә бару шактый мәшәкатьләр тудырса да, кәгазь һәм элемтә хезмәте бәяләре артса да, «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасына язылу бәясе элеккечә—елына 6 сум 24 тиен булып калды.

Әгәр сез үзегезнең район газетасына язылсагыз, райондагы, республикадагы, илдәге, чит җирләрдәге кызыклы хәбәрләрне укырсыз, гыйбрәтле язмышлар, төрле хәлләр белән танышырсыз.

Газетага һәр почта бүлекчәсендә, хат ташучылар аша язылырга мөмкин. Тик моны хәтерегездән генә чыгармагыз!

## 30 АВГУСТ—РЕСПУБЛИКА КӨНЕ—ЯЛ КӨНЕ ДИП ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ.

Татарстан ССР Югары Советының «Татарстан Совет Социалистик Республикасы төзелү көне турында» 1990 ел, 31 август карарын үтәү йөзеннән Татарстан ССР Министрлар Кабинеты 30 августны—Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителү көнен—ЯЛ КӨНЕ итеп игълан итте.

## Кара, чагыштыр, нәтиҗә ясa!

1991 елның 8 августына терлек азыгы хәзерләү буенча мәгълүматлар. Беренче багана—хуҗалыклар, икенче—печән, өченче— сенаж, дүртенче—үлән оны, бишенче салам (процентларда), алтынчы—бер шартлы терлеккә хәзерләнгән азык берәмлеге (центнерларда).

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 40 | 116 | 25 | 85 | 11,4 |
| Ульянов исем. | 97 | 108 | 43 | 94 | 11,6 |
| «Правда» | 56 | 258 | 65 | 91 | 16,7 |
| «Восход» | 63 | 211 | 22 | 30 | 12,8 |
| Мичурин исем. | 31 | 113 | — | 41 | 7,8 |
| «Россия» | 57 | 187 | — | 90 | 13,6 |
| Хафизов исем. | 66 | 151 | 35 | 28 | 9,8 |
| «Путь к коммунизму» | 63 | 79 | 22 | 27 | 6,3 |
| Муса Җәлил исем. | 81 | 187 | 14 | 120 | 14,7 |
| «Родина» | 71 | 138 | 36 | 46 | 10,0 |
| «Игенче» | 25 | 114 | 40 | 75 | 15,8 |
| «Большевик» | 113 | 172 | 24 | 40 | 14,3 |
| «Заветы Ильича» | 83 | 204 | 94 | 55 | 13,4 |
| «Знамя Октября» | 70 | 220 | 26 | 83 | 15,3 |
| «Алга» | 52 | 142 | — | 86 | 11,1 |
| «Комбайн» | 120 | 141 | 174 | 56 | 12,5 |
| XXI партсъезд исем. | 73 | 214 | 21 | 103 | 14,9 |
| «Татарстан» | 71 | 202 | 79 | 143 | 17,1 |
| «40 лет Победы» | 80 | 136 | — | 33 | 10,5 |
| «Чишмә» | 38 | 107 | — | 39 | 6,9 |
| «Таң» | 50 | 74 | — | 97 | 8,0 |
| «Москва» | 45 | 163 | — | 101 | 11,4 |
| «Үрнәк» | 72 | 124 | 28 | 46 | 8,8 |
| «Лесная Поляна» | 160 | 315 | — | 110 | 29,0 |
| «Кондырча» | 51 | 111 | 7 | 66 | 8,1 |
| Кузнецов исем. | 26 | 146 | 4 | 29 | 7,7 |
| «Заря» | 48 | 219 | — | 51 | 13,6 |
| «Чирмешән» | 67 | 188 | — | 73 | 12,7 |
| «Ленинский путь» | 73 | 113 | 74 | 50 | 9,9 |
| «Беренче Май» | 35 | 131 | 35 | 62 | 9,3 |
| «Төрнәс» совхозы | 127 | 114 | 27 | 72 | 12,7 |
| «Мамык» совхозы | 66 | 254 | 13 | 44 | 15,1 |
| «Рассвет» совхозы | 63 | 229 | 23 | 91 | 15,0 |
| «Сөлчә» совхозы | 49 | 147 | 14 | 63 | 10,2 |
| Хуҗалыкара берләш. | 76 | 48 | 90 | 98 | 2,7 |
| «Яшь көч» | 23 | 140 | — | 144 | 16,3 |
| Район буенча | 66 | 147 | 36 | 68 | 10,8 |

## ◆ Бер колхоз хәбәрләре

### Эш тәмамлана

«Заря» колхозында 60 гектарда тары, 65 гектарда бодай урып-җыясы калган. Колхозда бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның һәр гектары 16,8 центнер уңыш биргән. Корылык үзенекен итте, борчак һәр гектардан нибары 8 центнер гына чыккан. Ә менә солы—18,8, арыш—20,9 центнер уңыш биргән.

Комбайннар ашлык тоткыч, салам тапагычлар белән җиһазландырылган. Шуңа күрә дә ашлыгы урып-җыелган басулар чиста булып кала. Алар артыннан ук басуларга тракторлар төшкән. 340 гектарда уҗым чәчү өчен туфрак әзерләнгән, 360 гектарда туңга сөрү үткәрелгән.

### Орлык салына

Хуҗалыкта бу эш уңышлы башланып киткән. 1992 ел уңышы астына 1400 центнер орлык салынган. Уҗым җирләрен быел 650 гектарга җиткерү каралган. 1230 центнерда күчмә фонд бар. Борчак һәм солы орлыгы да салганнар бирердә.

В. АКМУРЗИН.

# ЗАМАНДАШЛАР ТУРЫНДА

## Гаилә бәхете

БЕР гаилә йөген тартучы ир белән хатынның бер үк коллективта хезмәт итүен һәм гомум йөкне дә бергә күтәрешүен күрү үзе бер күңелле хәл. Бигрәк тә ул тату, уңган гаилә булса. Сәйфетдиновлар гаиләсе нәкъ менә шундый гаиләләрдән санала. Гаилә башлыгы Минаҗетдин Минаф улы 1987 елдан бирле СМУда кранчы булып эшли. VI разрядлы машинист ул. Ә хатыны—Рәйханә Наил кызы IV разрядлы сылаучы-буяучы һөнәренә ия. М. Н. Маликова җитәкчелегендәге алдынгы бригадада эшли.

Минаҗетдин үзе—идарәнең футбол командасы уенчысы. Егетләр елның-елында уңышлы чыгыш ясыйлар. 1990 елда да шәһәр беренчелегенә ярышларда командабыз икенче урынны яулады. 4 ел дәвамында команда яшәрә, кешеләр алышына торды. Спортчы өчен гомернең узуы, еллар саны арту шатлык түгел-түгелен. Әмма бу хакыйкать Минаҗетдингә кагылмый. Ул әле бүген дә алыштыргысыз уенчы. Шунысын да әйтик, Сәйфетдиновлар гаиләсе идарәдә оештырылган спорт уеннарында теләп катнашалар. Уллары Фидаил һәм Руслан да әтиләре кебек спортка гашыйк. Бары аерма шунда гына—алар волейболны ярата-рак тәшәләр.

Ни генә булмасын ата-ананың матур үрнәге балаларында дәвам итә. Әти-әни булган кеше өчен яшәү мәгънәсе шунда түгелмени?!

Рәсемдә: кранчы М. Сәйфетдинов. Бүгенге көндә ул шәһәр үзәгендә 2 мең 150 квадрат метрлы сәүдә мәйданы булачак универмаг төзелешендә эшли.





## БЕЗНЕҢ МАРИЯ

—Бигрәк сөйкемле хатын. Кем соң бу?—дияләр фоторәсемен күрүчеләр.

Мария Никитовна Маликова ул. Безнең идарәгә 1979 елда килгән иде. Ул чагында II разрядлы сылаучы-буяучы белгечлегенә ия иде Мария. Ә хәзер ул—IV разрядлы оста, бүгенге көндә тапшырылу алдында торган объектта мастер вазифаларын башкара. Аның кул астында 25 кешедән торган сылаучы-буяучылар һәм 10 кешелек балта осталары бригадалары эшли. Алар Яңа Чишмәдә үзәк район больницасы бинасын төзиләр. Үзе дә эшне яратып башкаручы һәм зур осталыкка ия булган бу хатынны хезмәттәшләре ихтирам итәләр. Аның оештыру сәләтенә ия булуы, янәшәсендәгеләр өчен җан атып яшәве дә Марияны кешеләр күңеленә шулай якынайтадыр, мөгаен. Үз бригадасындагы һәр кешегә карата гаҗәеп игътибарлы ул. Һәркемнең нинди уй-хисләр белән яшәвен, нинди борчулар белән янганын каян белеп бетерәдер, бик гаҗәп. Әмма коллективта берәрсенең гаиләсендә шатлыклы вакыйга булса—гаилә кору, бәби туу, балаларның уңышлары яки бүтән берәр яңалыкмы—һәммәсе мәгълүм аңа. Котларга да, башкаларга хәбәр итәргә дә өлгерә, күңелне канатландырып җибәрердәй сүзен дә таба белә. Берәрсе фатир хакында кыенлык кичерәме яки бүтән мәшәкатьтән иза чигәме—янә дә Мариянең ярдәме бик вакытлы килеп өлгерә. Кирәк икән, урынлы таләбен белдереп, җитәкчеләр каршына барудан да тайчанмый.

Бу сөйкемле ханымның түм-түгәрәк тату гаиләсе бар, томырылып торган ике кызы үсә. Бар яклап та уңган-булган кеше юк ул дияргә яраталар. Бар ул андый кеше! Әнә—безнең Мария Никитовна! (рәсемдә).

**Г. СӨБХАНКУЛОВА.**
53 нче СМУ.

В. Никонорова фотосы.

## Якты йөз белән

**Ремонт-төзү участогы йортлар төзү, шәһәрдәге торак фондын ремонтлау һәм асфальт юллар салу белән шөгыльләнә. Коллектив июль аенда 309 мең сумлык эш башкарып планны үтәүгә иреште. Ә бүген сүз гомум уңышка аеруча зур өлеш кертүче бригадалар турында.**

**Юлларга асфальт җәюче комплекслы бригадада** (мастер З. Минһаҗев) 50 ләп кеше эшли. Аларның хезмәте сезонлы булуы белән башкалардан аерылып тора. Быелгы сезонда бригадага 1 миллион 400 мең сумлык эш башкарырга дигән план бирелгән иде. Бүгенге көндә аның 954 меңе эшләнде инде. Бригада быел «Үрнәк» колхозында 3 километрдан артыграк юл салды, шәһәрнең Островский урамында 4630 квадрат метрда ике катламлы асфальт җәелде. Куйбышев урамын тулысынча, Комсомольская, Бауман һәм Суворов урамнарын өлешчә асфальтлады. Хәзерге вакытта бригада «Ленинский путь» колхозында юл сала.

Комплекслы бригада егетләреннән асфальт-бетон заводы (АБЗ) электригы Р. Җиһаншин, АБЗ операторлары К. Гобәйдуллин, Р. Әбҗәббаров, шоферлар И. Иштуллин, И. Ганеев, С. Кубасов, асфальт таратучылар А. Тихонов, П. Савгачев, электр ярдәмендә эретеп ябыштыручы Г. Халитов, экскаваторчы Ә. Якупов коллективның ихтирамын казанган эшчеләрдән саналалар.

**Буяучы-сылаучы кызлар бригадасында** (мастеры В. Гыйззәтуллина) 24 кеше эшли. Алар шәһәрдә торак ремонтлыйлар. Июль аенда планда каралган 25 мең урынына 29 мең сумлык эш башкардылар. Бригаданың Л. Хәммәтова һәм М. Солтанова, Ф. Ильмухина звенолары аеруча тырыш.

**Ташчылар бригадасы** (җитәкчесе И. Хәсәнҗанов) егетләре бу көннәрдә К. Маркс урамындагы 3 этажлы (9 квартиралы) йортны төзеп бетереп киләләр. Моннан тыш Кормыш микрорайонында ике индивидуаль йорт төзелешендә дә алар эшли.

Гомумән, РСУ коллективы профессиональ бәйрәм көнен якты йөз белән каршылый.

**Н. ГЫЙЛЬФАНОВА,**
партоешма секретаре.

## Туар көнгә өмет бар

«ТНГФ» производство берләшмәсе ПМКсы (җитәкчесе Р. Я. Хәсәншин) төзүчеләр көнен эштә уңышлар белән каршылый. Узган айда без 140 мең сумлык эш башкардык. Коллективның күз текәп торган осталары, тырыш белгечләре аз түгел. Мастер Г.М. Ермолаев—шундыйларның берсе. Ул эшләгән объектта план үтәлеше һәм сыйфат өчен дә, коллективның татулыгы һәм бердәмлеге өчен дә кайгырмаска була. Чөнки аны хезмәттәшләренең олысы-кечесе ихтирам итәләр, ярдәм кирәксә—аңа таяналар, сүзенә-тәкъдименә колак салалар.

Ташчылардан И. Зарипов, Н. Ерышев, отделка эшләрен башкаручылардан Т. Синякова, Л. Имукова, Г. Әюпова, Л. Братусь һәм башкаларның тырышлыгы мактауга лаек. Балта осталары И. Җәббаров, Р. Бәширов, Р. Вәлитовлар да үз эшләренең осталары.

Гомум эшнең уңышлы баруында ПТО инженерлары В. И. Кальдяева, Т. А. Купченконың да өлеше зур. Төзүчеләрнең эшен нәтиҗәле оештыру, аны тиешенчә бәяләү һәм хезмәткә омтылышны кирәгенчә юнәлтә белү—башкаручыларга олы ярдәм булып тора.

Дөрес, төзүче хезмәте бик күп кул көче сорый ул. Механикалаштырылган эшләр аз әле бездә. Соңгы елларда төзү материалларына һәм җиһазлар өчен запас частьләргә кытлык үзен сиздерми калмады. Махсус белгечлеккә ия булган кешеләрне дә без теләгәнчә күп дип әйтә алмыйбыз. Эшләүчеләрнең яшәү-көнкүреш шартларын җиңеләйтү мәсьәләсе дә бүгенгәчә урынында кала килә. Әмма коллектив бу кыенлыкларның кайчан да булса җиңеләчәгенә ышанып, шуңа өметләнеп эшли. Күпме яхшырак эшләсәк, ул көннең шулкадәр иртәрәк килүенә өметләнү бу.

**Н. ПЕТРОВА,**
ПМКның партоешма секретаре.

## Тырышып эшлибез

**«Коопстрой» төзелеш участогы**ннан В. Чванов бригадасы хәзерге вакытта Якушкинода кибет бинасы төзи. Әлеге кибетнең сәүдә мәйданы 100 квадрат метр булачак. Авыл хезмәтчәннәре өчен бу күркәм бүләкне тизрәк өлгертү өчен тырышабыз.

Моннан тыш быел безнең участок район потребительләр җәмгыятенең ярдәмче хуҗалыгында ана дуңгызлар асрау өчен торак төзи.

Материал кытлыгына һәм эшче куллар җитешмәүгә дә карамастан, эш темпын киметмичә эшләргә тырышабыз.

**С. ГОМӘРОВ,**
профком рәисе.



Төзүчеләребезнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсе буларак шәһәребез көннән-көн үсә, яңара, матурлана бара.

Н. Квашнина фотосы.

**ТӨЗҮЧЕЛӘР ШАЯРТА**

«Бер кадак та сукканың
юк»,—диеп
Әйтәсез лә юкка бит,
дустым,
Салган чакта дача
төзелештән
Никадәрле кадак мин
«суктым».

**Ш. ШӘРӘПОВ.**

